СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» октябрь 2019 ел № 123

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Балтач шәһәр җирлеге Уставының 11 статьясы, «Балтач шәһәр җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану соравы буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2019 елның 19 сентябрендәге 116 номерлы Балтач шәһәр җирлеге Советының карары, «Балтач шәһәр җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану соравы буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2019 елның 19 сентябрендәге 77 номерлы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә 2019 елның 08 декабренә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«Балтач шәһәр җирлегендә яшәүче 18 яше тулган һәм референдумда тавыш бирергә хокукы булган гражданнарга 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул җыелган акчаларның түбәндә күрсәтелгән урындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына Сез ризамы:

- Балтач шәһәр тибындагы поселокта: Ленин, Киров, В.Булатов, И.Саляхов урамнарында җәяүлеләр өчен асфальт - бетон катламлы тротуарлар җәйдерү; Нариман – Г.Тукай – Школьная урамнары буенча су үткәрүче канау эшләтү;

- Көек авылында: Ибраһимов урамындагы юлга асфальт – бетон катламы җәйдерү

**ӘЙЕ** **ЮК**».

3. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономия барлыкка килгән очракта, Балтач шәһәр җирлеге Советы карары нигезендә янга калдырылган акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Балтач шәһәр җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач шәһәр
җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин